ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВАХИТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.28, д. им. М. Вахитова,
422575

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВАХИТОВ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Үзәк ур., 28 нче йорт, М. Вахитов исем авылы,
422575

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

30.01.2020 4379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1 № 3

д. им. М. Вахитова

**2020 елга Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәяләрен раслау турында**

«Күмү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 3 пункты һәм 12 статьясындагы 3 пункты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» 2020 елның 29 гыйнварындагы 61нче номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196нчы номерлы һәм «Тарифлар буенча Татарстан Республикасы Дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2010 елның 15 июнендәге 468нче номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары, Вахитов авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елның 1 февраленнән мәет җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә Вахитов авыл җирлегендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 6124,86 сум күләмендә 1нче кушымта һәм 2нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук Вахитов авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге башлыгы Ф.Р. Каримов

Вахитов авыл җирлеге
Башкарма комитеты
җитәкчесенең
2020 елның 30 гыйнварындагы
3нче номерлы карарына
1нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының
Вахитов авыл җирлегендә 2020 елның 1февраленә күмү буенча
хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән бәяләре исемлеге

| Хезмәтләрнең исеме | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Мәетне күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Мәет җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3 167,00 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 982,00 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1 975,86 |
| Барлыгы | 6 124,86 |

Вахитов авыл җирлеге
Башкарма комитеты
җитәкчесенең
2020 елның 30 гыйнварындагы
3нче номерлы карарына
2нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының
Вахитов авыл җирлегендә 2020 елның 1февраленә күмү буенча
хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән бәяләре исемлеге

| Хезмәтләрнең исеме | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Мәетне күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | — |
| 2. Кәфенләү | 586,00 |
| 3. Мәет җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2 581,00 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 982,00 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1 975,86 |
| Барлыгы | 6 124,86 |